Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Яуширмә авыл җирлеге Советы

КАРАР

2025 елның 27 марты № 54/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Яуширмә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Яуширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 27 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:


1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Яуширмә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга раслраларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, график сурәте белән бергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Яуширмә авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча чыгарырга:
Яуширмә авылы, Г.Исхакый ур., 9 йорт (административ бина);
Яуширмә авылы, Клуб ур., 8б йорт (мәдәният йорты бинасы)
3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Яуширмә авыл җирлеге
башлыгы Л.Р. Гәрәева

Чистай муниципаль районы
Яуширмә авыл җирлегенең
2025 елның 27 мартындагы
54/1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № т/б | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче Полевой | Яуширмә авылы<br>Полевая урамы 1 нче йорттан 30 нчы йортка кадәр | 57 |
| 2 | 2 нче Школьный | Яуширмә авылы<br>Полевая урамы 31А номерлы йорттан 44 нче йортка кадәр.<br>Школьная урамы<br>Речная урамы №2,№2а,№4,№8,№10,№12, №14, №19 йортлар | 56 |
| 3 | 3 нче Гаязов | Яуширмә авылы<br>Речная урамы №1, №3,№5,№7,№9,№11,№13,№15,№18,№20,№21,№22,№23,№25,№27,№29 йортлар<br>Г.Исхакый урамы | 60 |
| 4 | 4 нче Озерный | Яуширмә авылы<br>Клуб урамы,<br>Озерная урамы,<br>Верхняя урамы | 57 |
| 5 | 5 нче Колхоз | Яуширмә авылы<br>Механика урамы,<br>Дружба урамы,<br>Колхоз урамы,<br>Вәлиев урамы 54 нче йорттан 60 нчы йортка кадәр | 58 |
| 6 | 6 нчы Вәлиев | Яуширмә авылы<br>Вәлиев урамы 1 нче йорттан 53 нче йортка кадәр | 53 |
| 7 | 7 нче Садовый | Яуширмә авылы<br>Газопровод урамы,<br>Садовая урамы,<br>Нагорная урамы,<br>Овражная урамы | 52 |



ул. Садовая
ул. Верхняя
ул. Речная